# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче Иске Комазан торак пунктында 2024 елга үзарасалым кертү турында

№ 7 «19» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Иске Комазан торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Иске Комазан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (хатыны һәм 18 яшькә кадәрге балалары) күп балалы гаиләләр, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-Иске Комазан торак пунктында Тау асты урамы юлын вакташ җәеп ремонтлау(материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Иске Комазан торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

-Иске Комазан торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (махсус җиһазлар лампалары сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Дүсмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: /Р.М.Ефимов/